Зәй муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
“Түбән Биш урта гомуми белем мәктәбе”

Таҗетдин Ялчыгол исемендәге укытучыларның һәм укучыларның IV төбәкара фәнни-гамәли конференциясе

**Тема:** “Якташыбыз Мөдәррис Әгъләмов иҗаты”

**Юнәлеше:** Туган җир тарихы һәм аның данлыклы шәхесләре.


Фәнни – эзләнү эшен башкарды:
Түбән Биш урта гомуми белем мәктәбенең
11 нче сыйныф укучысы
Фархутдинова Рузилә Рөстәм кызы;
Фәнни җитәкчеләре:
Ахметвалиева Илзирә Изаил кызы
Түбән Биш урта гомуми белем мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
Шигабутдинова Гөлнара Риф кызы
Түбән Биш урта гомуми белем мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.


2019 ел

**Башлам өлеше**

Туган як, туган авыл, туган туфрак... Һәркемгә дә кадерле алар. Туган як гомер-гомергә кешеләр өчен яшәү көче һәм дәрт бирүче чыганак булып торган. Җир йөзендә һәр кеше үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, тарихын аеруча яхшы белергә тиеш.

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Әйе, безнең якташларыбызның күбесе районнан читтә - республика күләмендә һәм хәтта Россия күләмендә дә танылган шәхесләр. Без алар турында телевидение тапшыруларын карап, матбугат битләреннән укып та белә алабыз. Зәй төбәге - хисапсыз талантлар ягы. Әдип, тарихчы, табиб, дин галиме булган Таҗеддин Ялчыголның мирасы һәрдаим өйрәнелә. Шагыйрь М. Әгъләмов исеме поэзия сөючеләргә таныш. Кемнәр генә гаҗәеп әсәләр авторы Батулла иҗатына гашыйк түгел икән. Театр артисты Н.Дунаев иҗатына сокланмый мөмкинмени? Тагын бик күп талантларыбыз белән без горурланабыз.

Талантларыбыз бик күп, ләкин алар арасында күңелгә иң якыннары бар. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов шундыйларның берсе. Зәй ягы аның туган җире. Минем уйлавымча, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның юлын дәвам итә. Мөдәррис Әгъләмов иҗаты безне милләткә тугрылыклы булырга, кешелеклелеккә өйрәтә, татар халкыбызның йолаларына, гореф-гадәтләренә тарихына мәхәббәт тәрбияли. Мин үземнең чыгышыма “Якташыбыз Мөдәррис Әгъләмовның иҗаты” темасын алдым.

Фәнни-тикшеренү эшемә түбәндәге **максатларны** куям:

1. Зәй төбәгеннән чыккан шагыйрь буларак – Мөдәррис Әгъләмовның иҗаты турында тирәнрәк мәгълүмат алу.

2.Туган җиргә мәхәббәт, туган төбәккә бәйле күренекле кешеләргә хөрмәт һәм горурлану хисләре тәрбияләү.

**Төп өлеш**

Мөдәррис Әгъләмов шигырьләре һәм поэмалары татар халкының рухи бөеклеген раслый. Туган җиргә, аның тарихына олуг мәхәббәт, киләчәгенә үткен караш, замандашларының эчке дөньясы белән кызыксыну – шагыйрь иҗатында төп урынны әнә шулар алып тора. “Еракка китеп кара” исемле шигырьләр циклы әдәби мөхиттә кызыксыну уятты. Татар әдәбияты классиклары Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев кебек күренекле шагыйрьләр һәм язучылар Мөдәррис Әгъләмовның иҗатын бик югары бәяләделәр.Ул чын мәгънәсендә олуг, лаеклы халык шагыйре булды. Аның шигъри юллары миллионлаган укучылар йөрәгенә үтеп керә алды. Гадилеге, кояш кебек якты таланты аңа халык арасында зур танылу китерде.

Әлеге чыгышымны әзерләгәндә, мин Мәдәррис Әгъләмовның тормыш юлы белән тагын бер кат таныштым, ул йөргән сукмаклардан уздым. Мөдәррис Әгъләмов 1946 нчы елның 13 нче октябрендә Татарстанның Зәй районы Биш Субашы авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килгән. Авылның исеме генә дә ни тора – биш чишмәнең башланган урыны.1965 нче елда Түбән Биш авылындагы унберъеллык урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән. 1969-1973 нче елларда Тукай районының Яңа Гәрдәле авылындагы урта мәктәптә тарих укытучысы, шуннан соң Чаллы халык театрында режиссер ярдәмчесе булып эшләгән. 1974 нче елдан Казанга күченгәч, сәнгать белән профессиональ төстә шөгыльләнә башлый. Ул “Яшь ленинчы”, “Ялкын”, “Шәһри Казан” редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

Мөдәррис Әгъләмовның беренче шигырьләре 1959 нчы елда нәкъ менә “Яшь ленинчы” газетасында басылган.

Мөдәррис беренче класска укырга керәсе елны Биш Субашы авылына Мөнҗия исемле яшь укытучы килә. Кызу урак өсте. Август чилләсе. Укытучы апа өйдән-өйгә кереп укучылар белән танышып йөри.Мөдәррисләр дә моңа

әзерләнә. Гает көнендә генә эленә торган сөлгеләр эленә, өйләр яхшылап җыела. Мөдәррискә Һ.Такташның “Әүхәди” шигырен өйрәтәләр.

Мәдәррис аганың шагыйрь булуында Мөнҗия апаның да өлеше бардыр. Өченче сыйныфта укыганда Мөнҗия апа булачак шагыйрне Түбән Биш мәктәбенә алып төшә. Мөдәррис монда, Б.Рәхмәтнең “Ялкау, кире һәм иренчәк” әкиятен сөйләп, 1нче урынны ала.

Бер мең тугыз йөз илле сигезенче елның көзендә “Кызыл Зәй” газетасында уника яшьлек Мөдәррис Әгъләмовның “Истәлекләр” исемле шигыре басылып чыккан иде.

Сөббух Рәфыйков шагыйрьнең бу шигырен югары бәяли, мондый әсәрне уника яшьлек бала яза алмый, дип чыга. Уника яшьлек үсмер әнисенә багышлый бу шигырен.

Истәлекләр алар күп төрле,
Истәлекләр алар күп кала,
Бер истәлек булып әнкәмнең
Чиккән сөлгеләре саклана.

Чиккән сөлгеләре саклана,
Бизәге дә аның бизәге-
Карый сыман миңа бизәктән
Әнкәемнең нурлы күзләре.

“Әнкәй 38 яшендә, биш баласын калдырып китеп барды. Миңа тугыз яшь иде. Алла боерса, оҗмахта очратырмын мин бердәнберемне,”- дип яза ул әнисен искә алып.

Әйе, Мөдәррис Әгъләмов уника яшендә чып - чын шигырь язган. Ул инде беренче шигыреннән үк үзенең шагыйрь икәнен дөньяга белдерә.

Бервакыт Аккош күле буенда бер могҗиза була. Каләмдәшләре алдында Хәсән Туфан яңа шигырьләр укый. Әдипләр Хәсән Туфанның шигырь артыннан шигырь укуын үтенәләр. Алар барысы да, ул үз шигырьләрен укый,

дип уйлый. Соңыннан  сокландыргыч бу шигырьләр Мөдәррис Әгъләмовныкы икәне билгеле була. Хәйран калган язучылар аптыраганнан - йөдәгәннән сорап куялар:

- Кем соң ул Әгъләмов? – диләр.

Әле күптән түгел генә Зәй төбәгенең Түбән Биш урта мәктәбен тәмамлаган Мөдәррис Әгъләмов әнә шулай шаулап әдәбиятка кереп китә. Һәм шуннан бирле ярты гасыр диярлек шул шигърияткә, халыкка тугрылыклы хезмәт итә.

Ләкин аның  иҗаты бик җиңеллек  белән генә үсмәде, әлбәттә. Үзләрен бик югары тоткан әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр аның иҗатына ышанмыйча, кимсетебрәк карыйлар. Бәлки, аңлап кына бетермәгәннәрдер, шагыйрьнең олы сәләтен күреп бетермәгәннәрдер.

Әмма Мөдәррис Әгъләмовның иҗатын алай җиңел генә бетереп, үтереп булмый шул. Шагыйрь бар икән, ул тәнкыйтьләгән  саен ныгый гына бара.

Шагыйрьнең “Кан тамырын кистем” дигән китабы аның ата – анасы, Биш Субашы авылы, Түбән Биш мәктәбе һәм, гомумән, татар милләте алдында хисап тотуыдыр, мөгаен.

Мөдәррис Әгъләмов-безнең төбәктә туып-үскән, безнең мәктәбебездә белем алган шәхес. Без аның белән горурланабыз. Исемен шигърияттән, әдәбияттан аерып булмаслык, тумышы белән шагыйрь. Димәк, инде туганчы ук Ходай аның зиһененең нәкъ үзәгенә шагыйрьлек орлыгы салып куйган.

М.Әгъләмов турында сүз кузгалса, Тукай исеме телгә алынмыйча калмый. Чөнки, күпмедер дәрәҗәдә, М.Әгъләмовта да тукайлык яши. Аны, Г.Тукай шикелле үк, акча да, дан да, байлык та кызыксындырмый. Ул тормыш ваклыкларыннан өстен. Юкка гына аны “Туры Тукай” дип йөртмәгәннәр. Ул беркайчан да кемгәдер ярарга тырышып, кемгәдер охшатып язарга тырышмаган. Нәҗибә Сафина бер интервьюсында: "Мөдәррис Тукай белән сөйләшеп яшәде... Мөдәррис аның күп шигырьләрен яттан белде. Мин уйлыйм, ул Тукайда үзенә рухи сердәш, фикердәш, хәтта замандаш тапкан", - дип искәртә. Мөдәррис иҗатының эчтәлеге, язу стиле генә түгел, аларның яшәү

рәвешләре дә охшаш дияр идем мин. Алар икесе дә тормыш газапларын күп күргән, ачлы-туклы яшәгән чаклары да күп булган. Ләкин, вакытлар узу белән, язмыш аларга соңарып булса да яктылык бүләк итә. Алар татар халкының күренекле шагыйрләренә әверелделәр. Һәр татар кешесе Тукайны нинди бөек шәхес итеп белсә, Мөдәррис Әгъләмов иҗатын да белер, яратыр дип уйлыйм һәм шуңа өметләнәм.Чыннан да, Мөдәррис Әгъләмов – искиткеч талант иясе дияр идем мин. Аның иҗаты үзенә бер төрле үзенчәлекле, тирән эчтәлекле. Аның шигырьләреннән нindидер моң агыладыр шикелле. Юкка гына М.Әгъләмов – Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә һәм Татарстанның халык шагыйре кебек дәрәҗәле исемнәргә лаек булмагандыр.

2006 нчы елның октябрь аенда талантлы шагыйрьнең юбилее билгеләп үтелә. Бу тантанада Зәй делегациясе дә катнашта.Төркем җитәкчесе булган Габдулла Тукай исемендәге призга нәфис сүз осталарының республика конкурсы лауреаты Госман абый Мухамов: “Үзе исән чагында ук халыктан безнең заман Тукае дигән исем алган якташымны, мәктәптәшемне үзе язган “Зәйдән без” шигыре белән котлый алуым белән чиксез горурланам . Яшәсен шигырь, шигырь яшәсә, шагыйрь дә яши” –дип яза.

Без дә монда канат чыгарганбыз,
Без дә монда тамыр җәйгәнбез...
Шул сабыйлар бездән соң кабат
Кабатлансын иде:
-Зәйдән без!
Зәйдән без!

Мөдәррис аганың кайбер шигырьләре көйгә салынган. Аның «Серле йөрәк», “Карлар ява” җырларын кайларда гына җырламыйлар. Бу җыр буыннан-буынга күчеп бүгенге көндә дә халык күңелендә яши.

## Йомгаклау.

Шигырьләреннән күренгәнчә, якташыбыз нинди генә темага алынса да, аны ныклы өйрәнеп, ягъни үзләрен чолгап алган дөньяны, гомумән, тормышны өйрәнеп, бигрәк тә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итеп, шулар аша кеше күңеле, кичерешләре белән бәйле хәл-вакыйгаларны сурәтләргә, аларга олы мәгънә салырга ярата.

Күңелебездә рухи төшенкелек вакытында якташыбызның шигырьләр җыентыкларын кулыбызга алабыз һәм уйландыра, моңландыра, сөендерә, көлдерә торган әсәрләр бездә горурлану хисләре уята.

“Шигырь укып елый алганнарның

Күңелендә булмый каралык”, - дип язган бит Мөдәррис Әгъләмов.

Татарстанга күренекле язучылар, шагыйрьләр, сәнгать, мәдәният, Хезмәт алдынгылары биргән Түбән Биш ягы бүген дә тулы канлы тормыш белән яши. Безнең халык һәрчак белемгә, яктылыкка омтылган, киләчәк буынны да шул рухта тәрбияләгән. Тирә-ягыбызда милли рухлы кешеләр булганда, уңдырышлы Түбән Биш ягыннан әле байтак талант ияләре чыгар.

Шулай итеп, эзләнү эшен туплаганда кызыклы язмалар, фактлар өйрәнелде. Мин үземә күп мәгълүмат алдым. Хезмәтемне киләчәккә әзерлек дип тә кабул иттем. Якташларыбыз үзләренең иҗатлары аша безне туган телебезне, туган туфрагыбызны, үз нәселебезне, халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итәргә, яратырга һәм беркайчан да онытмаска чакыра.

“Чорлар аша хәбәр китерергә

Янып егылачак атлар чаба.

Яңа гасыр, әнә, капка ача-

Ахыргача барам, ахыргача!

**Кулланылган әдәбият:**

Мәктәп музеенда сакланган язмалар;

“Мәйдан” журналы №4, 2005 ел;

“Шәһри Казан” газетасы №112, 2016 ел;

М.Әгъләмов “Кан тамырын кистем”, 2001 ел;

М.Әгъләмов “Еракка китеп кара”2016 ел;

11 еллык урта мәктәпнең 11 сыйныфы өчен әдәбият дәреслеге.